"Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар"
(Коръән Кәрим. 2-256)

بسم الله الرحمن الرحيم

# Ислам нуры

№ 16 (644) 24 август, 2017 ел (1438, Зөлхиҗҗә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+

## Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның Корбан гаете белән котлавы



Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллахи вә бәрәкатүһ!

Мөхтәрәм җәмәгать!

Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык татарстанлыларны һәм дөнья мөселманнарын мөбарәк Корбан гаете белән ихластан котлыйм! Олуг бәйрәмебез — Корбан гаете барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын!

Корбан - шөкернең иң ачык чагылышларының берсе һәм Аллаһ тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган вә безгә кушып калдырылган изге гыйбадәт. Коръәндә бу хакта: "Раббың ризалыгына намаз укы. Корбан чал" (Кәүсәр сүрәсе, 2 нче аять), - диелә.

Без корбан чалганда шуны аңларга тиеш: Аллаһы Тәгаләгә корбанның ите дә, каны да кирәк түгел, Аңа безнең тәкъвалыгыбыз гына ирешә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: "Аларның (корбанга чалынган хайванның) ни ите, ни каны Аллаһыга түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына ирешә" (Хаҗ сүрәсе, 37 нче аять). Гыйбадәт савабы алу өстенә, мөселман кешесе мескен-фәкыйрьләргә дә хәл кадәре ярдәмен җиткереп, җәмгыятьнең бердәмлеген куәтләүгә үзеннән өлеш кертә.

"Хаҗ" сүрәсендә әйтә: "Без һәр өммәткә корбан чалуны тәртип иттек. Үзләренә ризык булырга тиешле, дүрт аяклы малларны корбан итеп чалганда Аллаһ исемен телгә алсыннар, дип. Сезнең Раббыгыз — Ул бердәнбер - Аллаһ. Шулай булгач, Аңа тәслим итегез. (Ий, Мөхәммәд) син ихлас күңеллеләрне һәм тыйнак итагатьчеләрне сөендер ("Хаҗ" сүрәсе, 34 нче аять)", - ди.

Бу көнне хаҗиларыбыз хаҗ гыйбадәтенең төп гамәлләрен тәмамлап, ихлас күңелләре белән Кәгъбада очраша. Кардәшләребез бөтен тормыш мәшәкатьләрен читкә куеп, туган җирләреннән меңләгән чакрым читтә Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәп хаҗ кыла, Аллаһы Тәгалә ризалыгына өмет багълап Корбан чалу йоласын башкара.

Пәйгамбәребез (ﷺ) бер хәдисендә әйтә: "Аллаһ каршында көннәрнең иң бөеге — Корбан бәйрәменең беренче көне", - ди. Бүген без дә миллионлаган мөселманнар кебек Корбан гаетенә шатланып, тәкбирләр әйтеп мәчетләргә җыелабыз һәм Аллаһка гыйбадәт кылабыз. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, татарстанлылар! Изге бәйрәмебез мөбарәк булсын! Раббыбыз һәммәбезгә дә иман байлыгы, саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете бирсен. Аллаһы Тәгаләгә барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирешергә, чалыначак корбаннарыбызның бәрәкәтен күрергә, бу дөньяда һәм ахирәт тормышында да бәхетле булырга насыйп итсә иде. Илебездә һәрвакыт тынычлык һәм бәрәкәт булсын!

## Корбан бәйрәме мөбарәк булсын!

Рәхимле, Мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән!

Мөхтәрәм дин кардәшләр!

Сезне, гаилә әгъзаларыгызны, туганнарыгызны ҮДО — Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Чаллы мөхтәсибәте һәм дә үз исемемнән мөбарәк Корбан бәйрәмебез — Гыйдүл-Әдха белән чын күңелдән тәбрик итәм!

Корбан бәйрәме - Исламның бишенче баганасы булган олуг хаҗның тәмамлану вакыты. Бу көнне изге Мәккә җирендә миллионлаган хаҗилар, шул исәптән шәһәрдәшләребез, җирдә тынычлык, иминлек, шәһәребездә бәрәкәт булсын өчен догалар кылалар. Аларның хаҗлары кабул булып, үзләренең исән-сау әйләнеп кайтуын телибез.

Корбан бәйрәме Ураза бәйрәме кебек үк социаль әһәмияткә ия. Ошбу бәйрәмдә без мохтаҗ кардәшләребезгә корбан итләребезне өләшәбез, садакаларыбызны бирәбез, аларны шатландырабыз, шул рәвешчә җәмгыятебезне тотрыкландырырга өлеш кертәбез. Корбан чалу мәзһәбебез буенча нисабы җиткән кешеләргә ваҗиб, ягъни тиешле гамәл. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Без сезгә терлекләрне корбан итүне йола итеп билгеләдек. Аныңда сезнең өчен зур файда бар" (22:36). Аллаһы Тәгаләгә чалган корбаннарыбызның ите дә, каны да кирәк түгел. Ул фәкать ошбу гыйбадәт белән тәкъвалыгыбызны, үзебезгә бирелгән нигъмәтләргә шөкер итә белү-белмәвебезне сыный.

Корбан чалу бәйрәмнең өч көнендә дә башкарыла. Өченче көннең ахшам намазыннан соң аны чалу ярамый. Корбанга чалынучы сарык, кәҗә 1 яшьтән, сыер исә ике яшьтән ким булмаска тиеш. Корбанлык өчен физик яктан сәламәт һәм көр булган мал гына сайлап алына. Сыер малын 7 кеше исеменнән чалырга мөмкин. Бер кеше исеменнән генә чалынса да дөрес. Корбан ите гадәттә өчкә бүленә. Аларның бер өлеше фәкыйрь-мескеннәргә, ятимнәргә, балалар йортларына, мәдрәсәләргә, икенче өлеше туганнарга, күршеләргә өләшенә. Ә өченче өлешен хуҗа үз гаиләсе өчен калдыра. Үзе хәлле булып тулаем мохтаҗларга бирсә, әҗере күбрәк була. Мохтаҗ гаилә корбан чалып, аны тулысынча үзе өчен тотса да дөрес була.



Татарстан мөселман-нары Диния нәзарәте казыяты быел Корбан нисабы күләмен 20 мең сум дип билгеләде. Гаиләдә артык 20 мең сум акча булганда, гаилә башлыгына корбан чалу тиеш була.

Корбан гаетен бәй-рәм итү шәһәребез мәчет-ләрендә 1 сентябрьдә иртәнге 06.00 сәгатьтә бәйрәм вәгазьләреннән башлана. Вәгазьдән соң гает намазы укыла, намаздан соң корбан чалына. Корбанлык сату һәм чалу - Сидоровка бистәсендәге элеккеге ит комбинатының мал кабул итү урыны янында ("Мясокомбинат" тукталышы). Мәчетләр янында корбан чалулар рөхсәт ителми.

Аллаһы Тәгалә чалган корбаннарыбызны һәм дә Үз ризалыгы өчен кылган барча изгелекләребезне кабул итеп алар өчен әҗер-савапларны арттырып бирсә иде!

Бәйрәмебез мөбарәк булсын!

Олы хөрмәт һәм изге догалар белән,

**Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе,
ҮДО - ТҖМ ДН Президиумы әгъзасы
Әлфәс хәзрәт Гайфуллин.**

# Корбан гаете вәгазе

Бисмилләһир-рахмәнир-рәхим!

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Мөхтәрәм дин кардәшләр!

Бүген без сезнең белән зур бәйрәм — Гыйд әл-әдха — Корбан гаетен каршы алабыз. Аллаһы Тәгалә барлык яхшы гамәлләребезне кабул итеп, гыйбадәтләребез өчен савапларын арттырып, ике дөньяда да Үзенең чиксез мәрхәмәтен насыйп итсә иде! Гаетебез мөбарәк булсын, һәр йортка да шатлык, иминлек һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен алып килсен!

Корбан — Аллаһ безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән сансыз нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү. Изге Коръәндә: "Раббың өчен намаз укы һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!"-диелгән (108:2).

Корбан чалуның асыл мәгънәсе корбан китерелгән хайванда, аның итендә түгел, ә күңдәмлек күрсәтү, тәкъвалык һәм диндарлыкта яшерелгән. Коръәндә: "Чалган корбаннарыбызның итләре вә каннары Аллаһка ирешмәс, ләкин сездән Аллаһыга тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер,"-диелгән.

Ел да корбан чалу — ул Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсыну һәм гыйбадәт хакына бар милкеңне корбан итәргә әзер булуның символик чагылышы.

Корбан чалу бай кешеләргә аларның Аллаһы Тәгалә каршында да, мөселман өммәте каршында да билгеле бер бурычлары барлыгын искә төшереп тора. Кеше ниндидер мөмкинчелекләргә ия икән, димәк, аларны үз байлыгыңны арттыру өчен генә түгел, ә изге максатларда кулланырга кирәк. Аллаһы Тәгалә бай кешеләргә мохтаҗ һәм фәкыйрьләрне кайгыртырга, бар кешеләр белән яхшы мөнәсәбәттә булырга омтылырга боера. Коръәндә: "Аллаһның Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә дә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми!"- диелгән ( 4:36).

Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) юкка гына: "Күршесе ач булганда тук булган (кеше) бездән түгел,"-дигән.

Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бу хәдисеннән кешегә, әгәр аның мөмкинлеге бар икән, башкаларга ярдәм күрсәтү җаваплылыгы йөкләнелгәне аңлашыла.

Корбан чалу кешеләр арасындагы аермалыкларны бетерә, аларны берләштерә, кардәшлек-дуслык җепләре ныгуга китерә. Чөнки бәйрәм көннәрендә мөселманнар якыннарына гына түгел, ә бар кешегә дә яхшы эшләре вә изге гамәлләре белән ярдәм итәргә омтыла, корбан итләрен тарата. Бу көнне һәр мөселман өендә кунакчыллык, шатлык, юмартлык хөкем итә. Балаларыбызда башка көннәр түгел, ә барыннан да бигрәк мөселман гаетләре шатлык, куаныч һәм бәхет хисләре тудырсын өчен, бу көннәрдә аларга бүләкләр бирү, татлы ризыклар белән сыйлау киңәш ителә.

Гает вакытында юмарт һәм гакыллы кеше күпләргә шатлык һәм куаныч китерә ала, ә иң мөһиме — Раббысының рәхмәтенә ирешеп, кайбер кешеләр гомере дәвамында да тоя алмаган җан тынычлыгына ирешергә мөмкин.

Бер хәдистә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) мондый сүзләре китерелә: "Саран кешеләрдән иң начары — моны эшләргә тиеш булып та, корбан чалмаучылары."

Пәйгамбәребез (с.г.в.) Корбан бәйрәмендә үзе ике корбан чала торган булган: берсен — үзе, ә икенчесен бар мөселман өммәте өчен. Шуңа күрә җитәрлек байлыклары булган мөселманнар тагы да күбрәк савап алырга теләсәләр, шулай ук ике яки аннан күбрәк корбан чала ала.

Шул рәвешле, корбан чалу мөэминнең үзенең рухи чистарынуын гына түгел, ә күпмедер вакытка булса да, мохтаҗларны ризык белән дә тәэмин итә.

Корбан гаетенең тарихына тукталып китик. Ул бөек пәйгамбәр, Аллаһның дусты Ибраһим (г.с.) һәм аның улы Исмәгыйль (г.с.) белән бәйле.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә (г.с.) зур сынау әзерли. Аңа үз улын корбан китерергә әмер итәлә. Ибраһим (г.с.) иң кадерле, көтеп алган һәм йөрәгенә якын булан кешесен корбан китерергә кирәклеген аңлый. Беләбез, Аллаһы Тәгалә Ибраһимга улын ул инде бик өлкән яшьтә булганда гына бирә.

Шушы бар кыенлыкларга карамастан, Ибраһим (г.с.) Аллаһы Тәгаләнең әмеренә карусыз буйсына. Әмма барча галәмнәр Раббысы беркемнең дә корбанына мохтаҗ түгел, һәм, әлбәттә, кеше үтерелүен теләми! Аллаһ әмеренә буйсынып, Ибраһим (г.с.) улы Исмәгыйль өстенә пычак күтәргәндә мондый сүзләр ишетә: "(Ий Ибраһим) төшеңдә күргән Безнең әмерне тәсъдыйк кылдың, үтәгән хөкемеңдә булдың. Әнә шулай Үзебезгә итагать иткән яхшы мөэминнәрне изге җәзалар белән нигъмәтлибез" ( 37:105).

Шул рәвешле, улы урынына корбан хайваны бирелә һәм Ибраһимга (г.с.) киләчәктә шулай ук пәйгамбәр булачак икенче улы Исхак (г.с.) бүләк ителә.

Корбан чалу — гыйбадәтнең бер төре һәм аны билгесез вакытка кичектерү дөрес түгел. Мисал өчен, кайберәүләр намазны, уразаны пенсиягә чыккач үти башлармын, баегач корбан чалырмын, дип әйтә. Бу дөрес түгел. Чөнки иртәгә нәрсә буласын беребез дә белми. Бик тәкъва кеше Хәсән Әл-Бәсри: "Көн киткәндә синең дә бер өлешең китә,"-дигән.

Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуның кыйммәтенә һәм әһәмиятенә килгәндә, мәшһүр Исмәгыйль Хаккы Бурсави язган "Рухул-бәйан" (1/363) тәфсиреннән бер гыйбрәтле хикәя китерергә мөмкин.

Шакик Әл-Бәлхи гыйбадәт юлына басып гыйлем алырга керешкәнче, һәрдаим христиан илләренә барып йөреп, сату эшләре белән шөгыльләнгән. Шундый сәфәрләрнең берсендә христиан короле аның күпме вакытын юлда үткәрүе белән кызыксынган. Шакик Әл-Бәлхи:

— Мин монда өч айда килеп җитәм, тагы өч ай дәвамында монда кирәк товарларны алам, өч ай туган җиремә кайтам һәм тагы өч ай товарларымны сатып бетерергә кирәк була,-дигән.

Король:

— Синең сәфәрләрең һәм сату эшләрең бер ел дәвам итә, Ә Раббыңа кайчан гыйбадәт кыласың соң? - дип сорый.

Бу сорау Шакик Әл-Бәлхига бик тәэсир итә, ул сату эшләрен калдыра һәм үзен гыйбадәткә багышлый.

Кеше нинди шартларда гына булмасын, нәрсә белән шөгыльләнмәсен, бу аның гыйбадәтенә зыян китерергә тиеш түгел. Һәм ул Аллаһ әмерләрен үтәргә тиеш. Эш, гаилә, балалар, кешенең яше дә гыйбадәткә комачауларга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә, эшләүчеләр гыйбадәт кылмаса да ярый, димәгән. Киресенчә, Коръәндә: "Янә белегез, малларыгыз вә балаларыгыз фетнәдер, әмма Аллаһ юлында булганнарга Аллаһ хозурында олуг нигъмәтләр бар, малларыгызны вә көчләрегезне Аллаһ юлына тотыгыз! Вә балаларыгызга дини тәрбия бирегез, ләкин аларга серләрегезне сөйләмәгез,"-диелгән (8:28).

Бу сүзләр өстендә уйланыйк, намазга, гыйбадәткә, котылуга ашыгыйк!

Ураза гаете, Корбан гаете намазларында, бу намазларның хөкеме вәҗиб булуга кармастан, мәчетләребезнең тулы булуы сөендерә. Ә көндәлек биш вакыт намазның хөкеме — фарыз. Мәзһәбебезнең имамы Әбү Хәнифә: "Фарыз вәҗибтән күк җирдән аерылып торган кебек аерыла,"-дип әйткән. Башкача әйткәндә, көн дә укыла торган биш вакыт намаз гает намазларыннан күпкә өстен.

Шул сәбәпле, хөрмәтле дин кардәшләребез, барчагызны Аллаһ йортлары-мәчетләребезгә - һәр намазга чакырабыз, ә булдыра алмасагыз, һәр җомга намазына. Гомер тиз уза, ә намаз - ул Кыямәт көнендә бездән беренче соралачак иң мөһим гыйбадәт.

Корбан чалуга килгәндә, корбан чалучы мөселман булырга, үз акылында булырга, бәлигъ булырга, ирекле булырга, сәфәрдә булмаска, нисаб күләмендә мал-мөлкәткә ия булырга тиеш. Корбан гаетнең беренче өч көнендә чалына. Әмма беренче көнне чалынса яхшырак. Гает намазы укылган шәһәрләрдә, торак пунктларында корбанны бәйрәм намазыннан соң чалалар. Ә бәйрәм намазы укылмый торган авылларда корбанны таң аткач чалалар. Сахих хәдистә: "Бүген (ягъни гает көнне) безнең беренче эшебез — (гает) намазын уку, аннан соң — корбан чалу. Моны үтәүче сөннәтебезне үтәр. Кемдер корбанны моннан (намаздан) иртәрәк чалса, бу үз гаиләсенә бирелгән гади ит булып саналачак,"-диелгән.

Төнлә корбан чалу макруһ, чөнки караңгыда кеше хата эшли ала, ә әгәр урын яхшы яктыртыла икән, макруһ хөкеме юкка чыга.

Бәйрәмнең өченче көненең ахшам намазыннан соң корбан чалырга ярамый.

Корбан чала белүче моны үзе эшли, әгәр чала белмәсә, башка мөселманга йөкли ала. Динсезләр һәм мәҗүсиләрнең корбан чалуы тыела.

Корбанга китереләчәк хайванны җәфаламас өчен сак булырга кирәк, пычак үткен булсын. Хайванның башын кыйблага каратып, сул як сыртына яткызу яхшы. "Бисмилла, Аллаһу әкбәр" сүзләрен әйтеп, хайванның бугазын, сулыш алу юлларын, муенындагы кан тамырларын кисәргә кирәк.

Хайванның җаны тәненнән аерылганчы, башын кисә яки тиресен туный башларга кирәкми. Корбан чалганда "Бисмилләһ" дип әйтү генә җитми, "Бисмилләһ, Аллаһу әкбәр" дип әйтү кирәк. Корбан чалучы аңлы рәвештә "Бисмилләһ, Аллаһу әкбәр" дип әйтмәсә, бу хайванның ите хәрамга әйләнә. Әгәр әйтергә онытса, бу гафу ителә.

Корбан итен өч өлешкә бүлсәң хәерлерәк: бер өлешен туганнарга һәм дусларга, икенчесен фәкыйрьләргә, ә өченче өлешен — үзеңә.

Корбан итеп чалынган хайванның итен һәм тиресен сату яки ит чабучыга түләр өчен куллану мәкрүһ, киңәш ителми. Тирене үзең куллансаң була, шулай ук аны мохтаҗларга яисә хәйрия оешмасына тапшырырга мөмкин. Мөселман булмаганнарга да корбан итен күчтәнәч итеп бирергә ярый.

Гает намазында хәзер янәшәбездә төрле шәһәр, ил, кыйтгалардан килгән мөселманнар, һәм, тышкы кыяфәтләребез, телләребез, тән төсебез төрле булуга карамастан, бер сафта торабыз, бер-беребезгә сәлам җиткерәбез, бер Аллаһка бергәләп гыйбадәт кылабыз. Ислам безнең йөрәкләрне берләштерде, бар мөселманнарны кардәш итте.

Раббыбыз шушы көнне ихластан дога кылырга, корбан китерергә, рухи тынычлык алып, Аның мәрхәмәтенә ирешергә насыйп итсә иде. Аллаһы Тәгаләдән безгә бәхет, сәламәтлек, илебезгә һәм Татарстан Республикасына тынычлык, иминлек, муллык һәм үсеш сорыйм. Гаетебез мөбарәк булсын!

**Камил хәзрәт Сәмигуллин,**
**Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, мөфти.**

# Аллаһның динен бөекләү

Ий Аллаһка иман китергән бәндәләр! Аллаһтан куркыгыз хакыйкый курку белән. Аллаһка тәкъва булыгыз. Тәкъвалык ул бөтен кешеләргә кагыла торган, Аллаһның васыяте һәм әмере, Аллаһ Тәгалә Коръәни кәримдә әйтте: **"Дәреслектә, без сезгә һәм сезгә хәтле булган китап әһелләренә - Аллаһка карата тәкъва булыгыз дигән васыятьне әмер иттек"** (Ниса, 131).

Аллаһ Тәгалә безгә барыбызга да Аның пакь динен бөекләргә әмер итте, чөнки динне бөекләү ул - фарыз булып тора.

Муаз ибн Джәбел, абу Барза һәм Әнәс ибн Мәлик (Аллаһ алардан разый булсын) сөекле пәйгамбәребезнең хәдисен риваять итәләр. Шушы хадистә сөекле пәйгамбәребез әйтә: *"Кайда булсаң да, Аллаһка карата тәкъва бул!"*

Тәкъва бул, ягъни Аллаһ сине күрә икәнен бел һәм шушы гыйлем сине Аллаһтан куркырга этәрсен, дигән мәгънәне аңлата.

Динне бөекләү ул - аны ихтирам итү. Аллаһның динен бөекләгән кеше турында, "Ул бөек отышка иреште",- дип әйтергә була, чөнки бу кешенең йөрәгенә Аллаһ Тәгалә иман белән тәкъвалыкны урнаштыра.

Динне бөекләүгә безнең хаҗәтебез бик зур. Аллаһның пакь дине ул Коръәндә һәм сөннәтә килгән бар нәрсәне үз эченә ала. Шуңа күрә берәр нәрсә Коръәндә яисә сөннәттә килсә, без аны бөекләргә тиеш. Чөнки бу калебләребездә иман булуына дәлил булып тора! Аллаһ Тәгалә Коръәни кәримдә әйтә: **"Әгәр дә берәү Аллаһның динен бөекләсә, ул үзе өчен яхшылык кылыр."**

Динне бөекләү ул - Аллаһның шәригатен хөрмәт итү, аны торгызу, аның буенча яшәү. Мөселман үз динен тиешлечә тотса, бу аның Аллаһның динен бөекләвенә дәлил булып тора һәм, киресенчә, диненә сүлпән булса, бу аның Аллаһның динен бөекләмәвенә дәлил булып тора. Алдагы аятькә таянып әйтергә була: кешенең Аллаһның динен бөекләве - иң элек үзе өчен яхшылык ул һәм, киресенчә, кемнеңдер динне калдыруы ул - иң элек шушы кеше өчен хәсрәт.

Икенче аятьтә Аллаһ Тәгалә әйтә: **"Кем Аллаһның динен бөекләсә, бу аның калебендә тәкъвалык сәбәпле булыр."**

Бөек галимебез Джассас "Ахкамул- Коръән" дигән хезмәтендә әйтә: "Гарәп теле галимнәре әйттеләр: "Шагаиру-Ллахи" дигән сүзнең мәгънәсе бөтен диннең галәмәтләрен үз эченә ала". Шулай ук әбү Бәкер ал-Гараби "Ахкамул- Коръән" дигән хезмәтендә әйтә: "Галимнәр арасында "шагаиру-Ллахи" дигән кәлимәнең тәфсирендә бернинди бәхәс юк, ул диннең галәмәтләре, аның әмерләре һәм тыюлары, дин белән бәйле урыннары һәм заманнары."

Сөекле пәйгамбәребез безгә үзенең хәдисләрендә динне бөекләүнең әһәмияттен аңлатты. Имам әл-Бохари үзенең сахих хәдисләр җыентыгында, Мисвар ибн Мәхрәмә дигән сәхәбәдән килгән хәдисне тапшыра. Шушы хәдистә сөекле пәйгамбәребез әйтә: *"Аллаһ белән ант итәм, әгәр дә Мәккә мөшрикләре мине тузан бөртеге кадәр микъдарда Аллаһның динен бөекләргә чакырсалар, мин аларның шушы сорауларына җавап бирер идем."*

Шулай итеп, мөэмин Аллаһның динен бөекләүдә, хакны торгызуда, хакны яклаганда, хак белән хөкем итүдә, хакны кабул итүдә җитез булырга тиеш. Боларның бөтенесе дә Аллаһның динен бөекләүгә керә. Сөекле пәйгамбәребез Мәккә мөшрикләренең соравына җавап бирүдә җитез иде. Берәр мөселман хакка чакырса, аны кабул итүдә тагын да җитезрәк булырга кирәк.

Шулай ук, мөселман үзе өчен башкалардан үч алуны калдыра икән, бу да аның хакны бөекләвенә дәлил булып тора.

Бөхари һәм Мөслим имамнары Гайшә р.г. риваятендә килгән хәдисне тапшыралар. Бу хәдистә Гайшә анабыз (Аллаһ аңардан разый булсын) әйтә: *"Аллаһ белән ант итәм, Аллаһның илчесе беркайчан да үзе өчен үч алмый иде, әмма Аллаһ куйган чикләрне узсалар, аның өчен генә үч ала иде".*

Шулай итеп, кем Аллаһның динен бөекли, ул беркайчан да үзе өчен башкалардан үч алмас, чөнки ул үзенең хакларын беркайчан да дин хакларыннан өстенрәк куймас, чөнки ул бeлә - аның хакы һәрвакыт Аллаһның хакыннан соң гына бара.

Кадерле дин кардәшем, динне бөекләү мәсьәләсендә үзеңнең карашыңны яңадан тикшереп чык. Имам ал-Байхакый үзенең "Шугаб ал-иман" дигән хезмәтендә яза: "Көннәрдән бер көнне бер кеше Хәсән әл-Басри янына килә һәм әйтә: "Мин Һиндстанга юл тотам, миңа бер васыять бирсәң иде." Хәсән ал-Басри әйтә: "Кайда булсаң да, Аллаһның әмерләрен бөеклә, шулай эшләсәң, Аллаһ сине бөекләр." Шуннан соң теге кеше әйтте: "Мин Хәсән ал-Басриның васыятен кабул иттем һәм Аллаһ мине өемә кире кайтканчы бөекләде."

Менә шулай булырга тиеш - мөселман даими рәвештә динне бөекләргә тиеш.

Мәсәлән, Аллаһ Тәгалә үзенең илчесе аша ирләргә сакал җибәрергә әмер итте икән, сакалыңны җибәр, шулай эшләсәң, синең турында бу кеше динне бөекли дип әйтергә була.

Имам әбү Ногайм үзенең "Хиляту әүлия" дигән хезмәтендә яза: "Сәгд ибн әбү Ваккас һәм Халид ибн Валид (Аллаһ алардан разый булсын) арасында фикер каршылыгы чыга. Һәм бер кеше Сәгд ибн әбү Ваккас янына килә һәм Халид ибн Валидне начар яктан искә төшерә башлый. Сагд ибн әбу Ваккас теге кешенең сүзен ишеткәч, әйтте: "Минем һәм Халид ибн Вәлид арасында булган каршылык, диннән өстен түгел! Ягъни безнең арабызда булган каршылык, мине үз динемне корбан итәргә беркайчан да этәрмәс."

Кайбер кешеләр бәхәсләшә башласа, үзенең динен корбан итә. Ничек корбан итәме? Ул, бәхәстә җиңәм дип, хыянәт итә, мәкерлек, золомлык кыла, ялган сүз әйтергә мәҗбүр була! Боларның бөтенесе дә, ничек тә булса бәхәстә оту дигән хискә алданып, динне корбан итүгә китерә!

Ий Аллаһның колы! Әгәр дә син берәр кем белән бәхәсләшсәң, сиңа динне саклап калу вәҗиб!

Чөнки дин ул бар нәрсәдән дә кадерлерәк!

Чөнки дин ул синең өчен бар нәрсәдән дә давамлырак!

Кадерле дин кардәшем динеңне сакла!

Нәфесеңә ияреп динеңне корбан итә күрмә! Нәфес бит ул даими рәвештә яманлыкны әмер итә! Бигрәк тә нәфес үзен мәзлүм итеп күрсә! Бәлки, чыннан да сиңа золомлык кылынгандыр, ләкин бу барыбер хәрәм кылып, динеңне корбанга китрену акламас.

Ибн Сәгд үзенең "Табакат" дигән хезмәтендә, шулай ук ибн Наср ал-Марвази һәм ибн Гасакир язып калдырдылар: Гомәр ибн Габделязис әйтте: "Әгәр дә минем тәнемне вак кисәкләргә турап юкка чыгарсалар, ә аның урынына бөтен сөннәт торгызылса һәм бөтен бидгәтләр юкка чыкса, мин шуңа риза булыр идем."

Ишеттегезме, тәкъвалы кешеләр динне ничек бөеклиләр?!

Күрдегезме, алар хак өстен булсын дип, үзләрен кызганмыйлар?!

Ибн әбү Хәтим үзенең тафсир китабында, ибн Мәсгудан килгән әсәрне китерә. Шушы әсәрдә ибн Мәсгуд әйтә: "Әгәр дә син: "Әй, иман китергән бәндәләр..,"- дигән аятьне ишетсәң, игътибарлы бул, колакларыңны торгыз, чөнки шушы аятьтән соң Аллаһтан берәр әмер килер яисә берәр нәрсәдән тыелу әмер ителер."

Шушы аять белән Аллаһ Тәгалә мөэминнәргә мөрәҗәгать итә, чөнки хакыйкатьтә алар гына Аллаһның әмерләрен үтәргә, тыелган нәрсәләрне калдырырга әзер.

Атаклы галимебез Шәмсетдин Абу Абдуллах Мөхәммәд ибн Абу Бәкер үзенең "Фаваид" дигән хезмәтендә яза: "Кеше өчен Аллаһның әмерләренә буйсынудан файдалырак нәрсә юк, ул аны башта мәшәкать итеп күрсә дә, аның нәтиҗәсе күп - хәерлелек, сөенү, бәхет. Шуңа күрә, мөэмингә берәр нәрсә әмер ителсә, ул аның нәтиҗәсенә карый, ягъни булачак әҗер-савапка карый. Аның мәшәкәтенә карамый, мин ул әмерне ничек үтәрмен микән, нәрсә минем турында кешеләр әйтерләр микән дип уйламый. Юк!

Аллаһның әмерләре килгәндә нәфескә урын юк!

Аллаһның әмерләре килгәндә җанның теләкләренә урын юк!

Без бит Аллаһның коллары! Аллаһ безгә берәр нәрсә әмер итсә, без аны үтибез, нәрсәдән тыйса, без аңа якын да килмибез!

Без Аллаһтан башка бер кемгә дә кол түгел!

Әгәр дә син бер Аллаһка гына гыйбадәт итүне тормышка ашырырга разый булсаң, Аллаһның әмерләре синең өчен кадерле, мөхтәрәм һәм бөек урында булыр!

Ий Аллаһның коллары, Аллаһның һәм Аның илчесенең әмерләренә җавап бирергә ашыгыгыз!

Атаклы галимебез Шәмсуддин Абу Абдуллах Мөхәммәд ибн Абу Бәкер давам итеп әйтә: "Һәм киресенчә, кеше өчен Аллаһ тыйган нәрсәләрне кылудан да зарарлырак әйбер юк, аның күңеле өчен ул ләззәтле булса да, аның нәфесенә ошаса да, чөнки аның ахыры аяныч һәм хәсрәт."

Кадерле дин кардәшләрем, бөек галимебезнең нәсыйхәтен кабул итегез, ул нәсыйхәт сезгә күп файда китерер.

Кайбер кешеләр Аллаһның әмерләрен үтәүне, Аллаһны бөекләүне, дин буенча яшәүне һаман кичектерәләр һәм төрле сүзләр белән акланалар!

Фетнәләрдән сак булыгыз!

Имам Әхмәд үзенең "аз-зухд" дигән китабында, табигыйннарның имамы абу Галиядән килгән әсәрне тапшыра. Шушы әсәрдә абу Галия әйтә: "Кешеләр өчен шундый заман килер, аларның калебләре бозылыр, алар коръән укырлар, ләкин аның ләззәтен татымаслар. Диндә берәр кимчелек кылсалар, аларның сүзе: "Аллаһ - кичерүче", - дигән сүз булыр, ә гөнаһ кылсалар алар: "Аллаһ безне гафу итәчәк."- дип әйтерләр. Аларның диннәре- башкаларны канәгатьләндерү.

Бөек имамның сүзен ишетәсезме!?

Мөхтәрәм дин кардәшләрем, шундый хәлгә төшүдән сак булыгыз!

Чын мөселман үзенең калебен гыйбадәтләр белән, Аллаһны ярату белән, Аңа тәвәккәл булу белән, Аллаһның әҗерләренә өметләнү белән - афәтләрдән терелтергә тырыша!

Аллаһны бөекләү нигезләргә таяна. Беренче нигез: Кем Аллаһны бөекли, шул динне дә бөекләргә тиеш, динне бөекләү ул - аның буенча яшәү белән башкарыла, ә кем Аллаһны бөекләми, беркайчан да аның динен бөекләмәс. Аллаһ Тәгалә имансызлар турында әйтә ("Әнгам" сүрәсе, 91 аять):

"Гафил кешеләр Аллаһны хак тиешле зурлау илә зурламыйлар. Шуның өчен Аның әмерләрен үтәмиләр."

Бөтен мофасирлар бу аять турында әйттеләр: бу аятьнең мәгънәсе - алар Аллаһ Тәгаләне тиешенчә бөекләмәделәр.

Ләкин мөселманнар андый түгел, алар Аллаһны тиешенчә бөеклиләр!

Аллаһны аз бөекләү белән имансызларга охшаудан сак булыгыз!

Икенче нигез: бел, синең кулыңда булган мал-мөлкәт, дәрәҗә, гакыл, гыйлем ул - сиңа фәкать динеңне торгызу, динне бөекләү, үзеңнең һәм башкаларның хакларын үтәү өчен генә Аллаһ тарафыннан бирелде. Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: **"Аллаһ мөэминнәрдән аларның җаннарын, мал-мөлкәтләрен сатып алды, ә аның урынына аларга җәннәтне бирде."**

Без җаннарыбызны, мал-мөлкәтләребезне Аллаһка саттык!

Шуңа күрә сак бул, дөнья сәбәпле пакь ислам динennән читтә калма!

Динне калдырып, дөньяга хезмәт итүдән сак бул!

Сак бул дөнья ләззәтләреннән!

Бүген күп кеше куган дөньяны без Аллаһка саттык! Әйе, дөнья безнең өчен, ләкин без аны ахирәт өчен кулланабыз, шуңа күрә без динебезне тиешенчә тотарга тырышабыз, Аллаһның ризалыгына ирешергә омтылабыз!

Бу һәм башка аятьләр бер хакыйкатькә дәлил булып торалар - дин беркайчан да куәтле булмас, иллә мәгәр син үз малыңны, җаныңны, куәтеңне, гакылыңны, дин хезмәтендә куллана башлаганчы! Син дин үсеш алсын өчен хезмәт итәсең икән, дөнья синең өчен хезмәт итәр! Ә менә дөнья өчен хезмәт итсәң, дөнья сине үзенә хезмәтче итәр!

Дөнья өчен кол булудан сак бул! Дөньяның хезмәтчесе булудан сак бул!

Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: *"Хәсрәттә*

*булыр дирхәм һәм динарның колы, ягъни акчаның колы, хәсрәттә булыр шулай ук матур кием колы. Әгәр дә аңа бирәр нәрсә бирсәләр, ул сөенә, бирмәсәләр, аның ачуы чыга.”* Шуннан соң сөекле пәйгамбәребез шундый кешеләр өчен хәерсез дога кыла: *“Шундый кеше хәсрәттә булсын! Аның өсте аска килсен! Әгәр дә аның тәненә шырпы кадалса, ул аны чыгара алмасын!”*

Ишеттегезме сөекле пәйгамбәребезнең догасын?!

Ишеттегезме, ничек дөньяга кол булган кеше түбәнчелеккә төшә?! Хәтта ул дөньяның колына әйләнә!

Шуңа күрә пакь динне бөекләү! Дөньяны бөекли күрмә!

Аллаһның нәфрәте төшкән нәрсәне бөекләмә син!

Динне, ахирәтне, Коръәнне һәм сөннәтне бөекләү!

Өченче нигез: Аллаһның ризалыгын эзләү һәм аңа ашкыну. Сөекле пәйгамбәребез әйтә: “Кем Аллаһның ачуын чыгарып, кешеләрне сөендерергә уйласа, Аллаһның да кешеләрнең дә ачуына иреше. Ә кем Аллаһның ризалыгын эзләп, кешеләрнең ачуын тапса, Аллаһ та, кешеләр дә аннан разый булырлар.”

Отышка ирешер шул кеше, кем Аллаһның ризалыгына ирешә алыр. Андый кеше дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле булыр. Аллаһ та, кешеләр дә аннан разый булырлар. Ә кем кешеләрнең ризалыгына ирешәм дип, Аллаһның ачуына төшсә, ул дөньяда да ахирәттә дә хәсрәттә булыр.

Гакыллы кеше Аллаһның ризалыгын сайлый, ә гакылсыз - кешеләрнең ризалыгына ирешәм дип, үз динен корбан итә. Ул динне тиешенчә тотмый, чөнки ул минем турында ни сөйләрләр микән, ни әйтерләр микән дип курка. Дөреслектә, кайбер кешеләр хәтта Аллаһтан разый түгел, әллә алар синнән разый булырлар дип уйлыйсыңмы? Әгәр дә син бер төркем кешеләрнең ризалыгына ирешсәң, икенче төркем кешеләр синнән барыбер разый булмас, шулай итеп, син күпме тырышсаң да, кешеләрнең нәфрәте астында булырсың. Шуңа күрә иң элек Аллаһның ризалыгына омтыл! Аллаһ сиңа ярдәмен бирер!

**Әбүбәкер хәзрәт Әбдиев,**
**Чаллының “Тәүбә” мәчете имам-хатыйбы.**

# Нәшрият өлкәсендә хезмәттәшлек



**9** августта “Ислам нуры” нәшриятында аның директоры Иршат хаҗи Шәйхаттаров һәм Кукмара мәдрәсәсе директоры Ришат хәзрәт Курамшин нәшрият өлкәсендә хезмәттәшлек итү буенча үзара килешүгә кул куйдылар. Бу чарада Кукмара мәдрәсәсе директоры урынбасары Айрат хәзрәт Шәфигуллин һәм “Ислам нуры” газетасы мөхәррире Хәлил Шәриф тә катнашты.

Ришат хәзрәт җөмһүриятебездә соңгы елларда дин тотучылар арасында тиз арада популярлык казанган тәҗвид дәреслеге авторы. Шулай ук инде 20 елдан артык Ислам матбугаты басмаларында аның публицистик язмалары дөнья күрә. Ришат хәзрәт үзен матур әдәбият өлкәсендә дә сынап карый. Аның дини хикәяләре “Бәхетле булырга вакыт” җыентыгы буларак укучыга иреште. Хәзер автор “Җаннарыбыз тынгылык эзли” дип исемләнгән икенче җыентыгын нәшриятка әзерли. Анда динебез кыйммәтләрен, исламча яшәү фазыйләтләрен, гади мөселманнар тормышын яктыртучы яңа хикәяләре тупланган.

Икеарадагы килешү нигезендә “Ислам нуры” нәшрияты беренче эш итеп Ришат хәзрәтнең Коръәннең Казан басмасына нигезләп язылган тәҗвид дәреслегенең яңартылган икенче тиражын нәшер итәчәк. Аны яңа уку елына — октябрь аена өлгертү бурычы куелган. Аннары авторның “Җаннарыбыз тынгылык эзли” дигән җыентыгы нәшриятка кабул ителәчәк. Ошбу хакта Ришат хәзрәт үзе болай ди: “Тәҗвид дәреслеген әзерли башлауга 20 еллап булды инде. Укыта башлаганда төп кыенлык дәреслекләр җитмәүдә иде. Бу эшкә үзебез алындык һәм төрле-төрле фәннәрдән дәреслекләр төзедек. Соңрак төрле уку әсбаплары күренә башлады үзе, тәҗвид буенча да китапчыклар басылып чыкты. Ләкин алар иске татар теленә нигезләнеп язылган, хәзерге укучыга бигүк аңлашылып бетми иде. Без тәҗвид кагыйдәләрен халык теле белән гади итеп аңлатуны үзебезгә максат итеп куйдык. Яңа дәреслегебез мәчет каршындагы курсларда кулланыла торган Әхмәтһади Максудиның “Мөгаллим сәни” китабына һәм Коръәннең Казан басмасына йөз тотып эшләнде. Еллар узган саен бу дәреслек эшкәртелеп, камилләшә барды. Аны әзерләгәндә “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе мөгаллиме Камил хәзрәт Вәлиуллин, Диния Нәзарәтенең Коръәнне өйрәнү үзәге җитәкчесе Илнур хәзрәт Хәйруллиннар үзләренең киңәш-тәкъдимнәре белән зур ярдәм күрсәттеләр. Былтыр Татарстан Диния Нәзарәте каршындагы Голәмәләр шурасы бу хезмәтемне тикшереп, аңа уңай бәя бирде һәм мәчетләр каршындагы курслар өчен Тәҗвид фәне буенча төп дәреслек итеп тәкъдим итте. Хикәяләр җыентыкларыма да укучылар битараф калмас дип ышанасым килә”.



**Рәсемнәрдә:** килешүгә кул кую; “Ислам нуры” басмаханәсе белән танышу.

# Хаҗ сәфәренә озату

**18** август кичендә Чаллы мөхтәсибәте аша “Стандарт-тур” белән хаҗга баручыларны изге сәфәргә озату чарасы үтте. Алар “Нур-Ихлас” мәчетенә ястү намазына җыелдылар. Аннан соң олуг хаҗга ниятләүчеләр белән саубуллашу булды. Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт хаҗга җыенучыларга җиңел сәфәр, хәерле гыйбадәтләр теләде, үгет-нәсихәтләрен бирде. Аннан соң төркем автобуста Казан аэропортына юл тотты. Алар иртәнгә 07 сәгатьтә Җиддә аэропортына очачаклар иде. Төркем 13 кешене, шул исәптән 7 ир һәм 6 хатын-кызны үз эченә алды. Ошбу хакта мөхтәсибәтнең хаҗ буенча җаваплы хезмәткәре Фәүисә хаҗия Нуретдинова болай ди: “Быел мөфтияттән яшь мөгаллимнәргә хаҗ кылу мөмкинлеге тудырдылар. Безнең мөхтәсибәттән ике яшь имамыбыз ошбу исемлеккә керде - Айдар һәм Камил хәзрәтләр. Камил хәзрәтнең Азнакай төбәгендә узган Коръән бәйгесендә җиңеп олуг хаҗга юллама алуга ирешкән бертуган энесе Рамазан да бирәдә иде. Алар бер самолетта очасы булдылар.

Быел безнең мөхтәсибәт аша 40 кеше хаҗ кыла. Калганнар “Эконом-тур” аша (аның 3 варианты бар). 23 августта соңгы ике кешене озатабыз.

Хаҗиләребез исән-сау әйләнеп кайтсын дип телик. Аннан соң гомрә хаҗларга һәм киләсе олуг хаҗга әзерлек башланачак.”

# Ислам дине белән кызыксынучыларны “Әл-Каләм” чакыра




**18** августта Чаллыда тагын бер Ислам товарлары кибете ачылды. Аның адресы: Яңа шәһәр, 43/05. Ошбу “Әл-Каләм” кибетен ачу тантанасы җомга намазыннан соң үтте. Анда шәһәр имамнары, Ислам дине белән кызыксынучылар катнашты. Беренче сатып алучыларга бүләкләр бирелде, чәй эчү оештырылды, ә урамда балаларга тәмле ризыклар таратылды.

**Рәсемдә**: кибет урнашкан бина тыштан.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы**
**ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы,**
**Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**24 август 16 сәг.**
**фактта 24 август 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**